**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «12» декабреннән № 87

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 26 октябрендәге 61 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының «Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 26 октябрендәге 61 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә

а) Яңа Чишмә муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның вазифаи тәртибенә куелган таләпләрне үтәүгә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибендә:

- 3 пунктта «җиде эш көне» сүзләрен «30 көн» сүзләре белән алыштырырга;

- түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.1. Әлеге нигезләмәнең 11 пунктында каралган нигезләнгән бәяләмәдә

түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты б пунктында күрсәтелгән гаризаларда һәм хәбәрнамәдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) федераль дәүләт органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан запрослар нигезендә алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 2 пунктының «б» пунктчасында күрсәтелгән гаризаларны һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча мотивацияләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 15 пункты нигезендә бер карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

- түбәндәге эчтәлекле 3.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча йомгаклау һәм аның нигезендә кабул ителгән карар комиссия әгъзаларына якындагы комиссия утырышында җиткерелә. Гариза яки хәбәрнамә тапшырган затка кабул ителгән көннән алып 15 көн эчендә кабул ителгән карар турында язмача мәгълүмат бирелергә тиеш».

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **В.М. Козлов**